ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
"АКСУБАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ"
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ
«АКСУБАЕВСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН»

**СОВЕТ**
**СТАРОКИЯЗЛИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**

**423073, Республика Татарстан, Аксубаевский муниципальный район, село Старые Киязлы, ул. Центральная д.56**

**Тел. (8-84344-4-30-39) ОГРН 1061665002332, ОКПО 94318671, ИНН/КПП 1603004832/160301001**

# КАРАР

№ 14 2021нче елның 12 нче мае

Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Кыязлы авыл җирлеге Советының 18.07.2014 елдагы 10 нчы номерлы карары белән расланган "Иске Кыязлы авыл җирлеге" муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару Кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында ( 01.10.2019 елдагы №85, 13.07.2020 елдагы №109 карарлар нигезендәге үзгәрешләр белән)

«Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында" 27.12.2009 елдагы 472-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Аксубай муниципаль районы Иске Кыязлы авыл җирлеге Уставы нигезендә Аксубай муниципаль районы Иске Кыязлы авыл җирлеге Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Кыязлы авыл җирлеге Советының 18.07.2014 елдагы 10 нчы номерлы карары белән расланган "Иске Кыязлы авыл җирлеге" муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару Кагыйдәләренә ( 01.10.2019 елдагы №85, 13.07.2020 елдагы №109 карарлар нигезендәге үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- Кагыйдәләрнең 29 маддәсендәге 5 пунктының 4 абзацында "РФ Шәһәр төзелеше кодексының 55 статьясындагы 6.2 өлеше нигезендә "капиталь төзелеш объекты мәйданын үзгәртү очракларыннан тыш" сүзләрен өстәргә;

- Кагыйдәләрнең 29 маддәсендәге 5 пунктындагы 5 абзацында "проект документациясе" сүзләреннән соң, РФ Шәһәр төзелеше кодексының 55 статьясындагы 6.2 өлеше нигезендә "капиталь төзелеш объекты мәйданын үзгәртү очракларыннан тыш" сүзләрен өстәргә.

- 30 маддәнең 5,6 пунктларында "утыз көн" сүзләрен «егерме биш көн» сүзләренә алмаштырырга.

- 30 маддәнең 3 пунктында түбәндәге эчтәлекле 6 һәм 7 пунктлары белән өстәргә:

6) башкарма хакимиятнең вәкаләтле федераль органы яисә Россия Федерациясе тарафыннан төзелгән һәм Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан кабул ителгән территорияне комплекслы үстерү турындагы карарны гамәлгә ашыруны тәэмин итүче юридик зат белән (алга таба - Россия Федерациясе тарафыннан билгеләнгән юридик зат белән);

7) территорияне комплекслы үстерү турындагы Карар кабул иткән Россия Федерациясе субъекты, җирле үзидарә органы, Россия Федерациясе субъекты тарафыннан төзелгән һәм Россия Федерациясе субъекты тарафыннан кабул ителгән территорияне комплекслы үстерү турындагы карарны гамәлгә ашыруны тәэмин итүче юридик зат (алга таба - Россия Федерациясе субъекты тарафыннан билгеләнгән юридик зат), йә территорияне комплекслы үстерү турындагы карарны гамәлгә ашыру максатларында территорияне комплекслы үстерү турында шартнамә төзелгән зат белән.

2. Әлеге карарны Иске Кыязлы авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә, Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында (http://aksubayevo.tatarstan.ru) һәм хокукый мәгълүмат рәсми сайтында (//http:pravo.tatarstan.ru) закон белән билгеләнгән срокта бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен узем контрольдә тотам.

Совет Рәисе,
Иске Кыязлы авыл җирлеге башлыгы: Г.Г.Дәүләтшин